Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№3 (25)

Декабрь, 2017 нче ел

## Бу санда:

*Хуш киләсең, 2018 нче ел!* 1

*Россиядә ничә кыш бабай яши?* 2

*Мин кышны ни өчен яратам?* 2-3

*Булат - иң шәп татар егете* 4




*Котлы булсын*
*Яңа ел!*
*Гел шатлыктан*
*торсын ул,*
*Бәхетле һәм мул*
*тормышка*
*Күрсәтсен юл яңа*
*юл.*

*Яңа ел котлы*
*булсын!*
*Чыршылар*
*балкып торсын!*
*Йолдызлар да,*
*елмаешып,*
*Игелек теләп*
*торсын!*

## ХУШ КИЛЕСЕҢ, 2018 НЧЕ ЕЛ!

***2018 нче елны каршы алганда, гимназия директоры А.Ф.Мирзаянов белән әңгәмә тәкъдим итәбез.***

**2017 нче ел үтеп бара. Азат Фәритович, бу ел нинди уңышлар алып килде?**

*2017 нче ел истәлекле вакыйгаларга бай булды. Гимназия базасында “Ел укытучысы - 2017” республика бәйгесенең зона этабы узды. Муниципаль этапта 5 укытучыбыз призер булса, зона этабын уңышлы үтеп, инглиз теле укытучысы Р.Г.Кадыйрова финалда катнашты. Аннары, бөтен район өчен истәлекле вакыйга – мәгариф хезмәткәрләренең республика август киңәшмәсе кысасында гимназия базасында шактый күп чаралар оештырылды. Гимназия бинасын, уку кабинетларын, территорияне төзекләндерү, җиһазлау буенча күләмле эш башкарылды. Мондый җитди чараларда активлык күрсәткән укытучылар коллективына, техник хезмәткәрләргә, укучыларга, ата-аналарга зур рәхмәтемне җиткерәм.*

**Чебешләрне көз көне саныйлар, дисәләр дә, саннар белән күрсәткечләр ничегрәк икән?**

*Мәктәп системасы ел дәвамында барлык төр күрсәткечләр буенча гел хәрәкәттә. 2017 елда Э.В.Тимергалиева “Укытучы-эксперт”, В.Г.Семенова, И.В.Латыйпова, Л.Ә.Фәхертдинова “Педагог-остаз”, Л.Ф.Бариева “Өлкән укытучы”, А.Ф.Мирзаянов “Оста мөгаллим” грантына ия булдылар. Р.Р.Мөхәмәтдинова “Ел сыйныф җитәкчесе”, Л.Г.Мортазина “Авыл укытучысы” конкурсы җиңүчеләре булды.*

**Укучыларның уңышлары – укытучыларның тырыш хезмәте нәтиҗәсе. Сәләтле балалар белән эш күрсәткечләрегез нинди?**

*Әлбәттә, укытучының фидакарь хезмәте балаларда чагыла. Сәләтле укытучы сәләтле бала тәрбияли. Укучыларыбызның уңышлары да сөенерлек. Муниципаль олимпиадаларда 119 бала җиңүче һәм призер булса, республикада 10 укучы призер булды, А.Фәхертдинова биология буенча республика командасы составында Бөтенроссия олимпиадасында катнашты. Ике укучы “Илһам” Бөтенроссия иҗат бәйгесендә җиңүче булды. 200 дән артык укучы республика һәм төбәкара фәнни-практик конференцияләрдә, төрле конкурс-бәйгеләрдә катнашып, призлы урыннарны алып кайттылар. “Сәләтле балалар” район фестивалендә 53 укучыбыз махсус премиягә ия булды.*



*Спорт буенча да уңышларыбыз шактый. Гимназия командасы ике ел рәттән Бөтенроссия Президент уеннарында уңышлы чыгыш ясый, И.Гәрәев билбау көрәше буенча ТР чемпионы, Р.Сафиуллин РФ чемпионы булды. Яңа 2018 нче елга да зур өметләр белән аяк басабыз. Бүгенге көнгә 128 укучыбыз төрле фәннәр буенча олимпиада җиңүчеләре һәм призерлары булдылар. Республика олимпиадаларында үз белемнәрен күрсәтә алырлар дип өметләнәбез.*

***Барлык хезмәттәшләремне, ата-аналар, балалар коллективын Яңа 2018 нче ел белән тәбрик итәм. Һәрбарчабызга иминлек, сәламәтлек, зур уңышлар, шатлыклар алып килсен ул!***

***Укучылар үзидарәсе***

## РОССИЯДӘ НИЧӘ КЫШ БАБАЙ ЯШИ?

### Рус Кыш бабае – Дед Мороз



Рус Кыш бабае Россиянең Вологодск өлкәсе Бөек Устюг шәһәрендәге үзенең зур биләмәләрендә оныгы – Кар кызы – Снегурочка белән яши. Әкиятләрдә сөйләнгән Суык бабай салкыннар алып килүче, бөтен дөньяны туңдырып, карга күмүче усал герой итеп сурәтләнсә дә, халык арасында Кыш бабай кызыл тун кигән, кулына таяк тоткан, Яңа ел алдыннан балаларга бүләкләр өләшүче ак сакаллы ягымлы карт булып танылган.

*Илебездә нинди милләтләр яшәсә – Кыш бабайлар да шул кадәрдер, әлбәттә. Төрле исемнәр белән аталып йөртелгән милли Кыш бабайларның тарихы һәр халыкның борынгы мәдәниятенә үрелгән.*

### Эхээ Дьыл



Якут халкының яраткан Кыш бабае – Эхээ Дьыл – мәрхәмәтле карт. Ул хатыны, балалары, оныклары белән бергәләп зур гаилә булып яши.

### Татар Кыш Бабае



Татар Кыш бабае Татарстанның Арча районы Яңа Кырлай авылында гомер кичерә.

Кыш бабай янында һәрвакытта аның кызын – Кар кызын күрергә мөмкин. Кыш бабай яшел тун, түбәтәй, чигүле күн читек кия.

Ел саен 15 декабрьдән башлап февральгә кадәр Кыш бабай татар әкиятләре геройлары белән Кырлай авылында кунаклар көтә.

***Дәвамын укыгыз:***
http://maydan.tatar/rossiyade-niche-kysh-babaj-yashi/

## МИН КЫШНЫ НИ ӨЧЕН ЯРАТАМ?

### Лиана Хәбибуллина:



Быелгы кышны ничек көткәнемне белсәгез иде сез! Минем кебек беренче карны көтеп алучы булды микән?! Беренче яуган кар бер генә төнлек торды да эреп суга әйләнде. Сеңлем белән ясап куйган Кар Бабай, иртән торуга, башындагы чиләген бер, борынына куйган кишерен икенче якка тәгәрәтеп, күл хасил итеп җәелгән иде...

Менә без бүген дәрестә утырабыз. Геометрия... Завуч укыта безгә бу фәнне. Укытучы таләпчән. Тып-тын. Бөтенебез баш та күтәрми мәсьәлә чишәбез. Тәрәзәгә күз салсам, ни күрим: талгын гына бөтерелеп, җиргә ябалак кар төшә! Чак кына кычкырып җибәрми тыелып калдым! Мәсьәлә кайгысы калмады! Кайчан кыңгырау чылтырар, урамга чыгып чабар идем!

Әһә, укытучы үзе дә, сокланып, кар яуганын күзәтә! Йөзе яктырып, балкып, тагын да чибәрләнеп киткән, бер усаллыгы да калмаган кебек тоела. ...Карадым да, хыял диңгезенә чумдым. Менә без икәү – Лира Нурфаязовна һәм мин – рәхәтләнеп йомшак карны учлап-учлап күккә чөябез, бер-беребезгә йомарлап атабыз, көлә-көлә карда тәгәрибез... Ул арада колагыма каяндыр "ВАС почмагы.... перпендикуляр....биссектриса..." дигән сүзләр керә, алар кар бөртекләре булып битемә куналар, күзләремә керәләр, иренемдә эреп юкка чыгалар....

"Лиана," – дигән тавышка сискәнеп китәм... Янымда укытучым – әле генә минем белән кар йомарламнары атышкан укытучым басып тора. Миемә кан йөгерә, баш берни эшләми. Классташларымның хихылдаган, нидер пышылдаган тавышлары колакка керә. Әһә, укытучы мине такта янына чакыра икән. Бетте, кар явуның бөтен рәхәтен бетерде бу апа. Үземне дөньядагы иң бәхетсез кеше итеп тоеп, әкрен генә такта янына атладым. Я Аллам! Кыңгырау! Иң кирәкле моментта шалтырадың син, кыңгырау! Бу тавышның никадәр рәхәтлек биреп шалтыравын белсәгез иде! Ура! Тәнәфес! Ура! Беренче кар! Без дәррәү коридорга, аннары баскычтан холлга, ишекләрне ачып тышка чыгып йөгердек. Исәнме, беренче кар! Исәнме, Кыш!

### Ислам Гайнуллин:

Минем өчен иң рәхәте – Кыш Бабай бүләген ачу. Акылым белән Кыш бабай булуына ышанмасам да, нишләптер шул бүләкне һаман көтәм. Әти-әниләр дә һаман безне кызыктырып, ел саен саллы бүләкләр әзерлиләр. Тимераяк, чаңгы бар, телефон булды, быел нинди сюрприз көтә икән?..

# МИН КЫШНЫ НИ ӨЧЕН ЯРАТАМ?

**Алина Исламгалина:**



Без һәр ел саен “Ян” спорт-сәламәтләндерү комплексына барабыз. Әти-әниләр тау чаңгысында шуа, апам белән без сноубордта төшәргә яратабыз, энем тюбинг белән шуа. Биек тау өстенә менү өчен, махсус канат юлы салынган. Иртәннән алып караңгы төнгә кадәр тауда шуып, кыш буена җитәрлек ләззәт алып кайтабыз.

Кышкы озын кичләрдә без үзебезнең Мөслимдә дә шуар өчен рәхәт урыннар табабыз. Иске Авыл тавы, Имәнәй тавында, карьерда тау шуу искиткеч рәхәт. Биек таудан җилдәй очып төшәсең, күзләргә кар тула, битләр кызышып яна башлый. Шулай булса да, беркем дә кайтырга ашыкмый. “Соңгы тапкыр шуабыз”, - дип, үз-үзебезне алдап, ничә тапкыр шуып төшәбез микән?! Шуннан да рәхәт уен юктыр.

**Ранис Сөләйманов:**

Быел көз белән кыш тартышы бик озакка барды. Кышны сагынып көтеп алдык. Табигать искиткеч матурланды. Агачларны бәс сарды. Көндезге кояш нурларында алар күзне чагылдырып җемелдиләр.

Мин кар бөртекләренең салмак кына җиргә төшүен күзәтергә яратам. Кич белән урам лампалары яктысында кар яуганны күзәтеп тору бик рәхәт. Караңгы төнне кисеп алып, шул лампочка астына гына каяндыр кар коела кебек тоела миңа. Кулларымны сузып, бияләйгә төшкән аерым кар бөртекләрен күзәтәм. Нинди генә матур фигуралар юк анда?! Бер-берсен кабатламый торган матурлык! Тып-тын калып, шушы матурлыкка сокланам. Күңелем саф, дөнья матур, яшәү рәхәт!

**Шамил Баянов:**

Мин кышны салкыннары, саф һавасы, күзләрне чагылдырып ялтыраган ап-ак карлары өчен яратам. Минем яраткан спорт шөгылем дә кыш белән бәйле. Кар яуганчы ук тимераякларымны әзерләп куям. Боз гына кирәк. Мәктәп янында шугалак катырганны түземсезлек белән көтеп алабыз. Кар күп яуса, карны көрибез. Кыш көне сыйныфташлар белән тау шуарга бару, чаңгыда йөрү өчен рәхәт. Җепшек көннәрдә кар тәгәрәтеп сыннар ясыйбыз. Кышның бөтен рәхәте шунда! Безнең гаиләдә биш кешенең туган көннәре кыш айларына туры килә. Минем туган көнем дә кыш көне.

**Диләрә Нуриева:**



Кышкы матурлык күңелләрне, күзне иркәли. Керфекләргә, чәчләргә күбәләк карлар килеп куна. Качып кына бер уч карны бияләй башына элеп аласың да, беркем күрмәгәндә ялт итеп ашап куясың... Әәәх, могҗиза... Яратам да шул ап-ак карны. Аптырыйм: өлкәннәр шуны аңламый. Янәсе, тамагың авыртыр...

Тагын ни өчен кышны яратам, дисезме? Коры суыкларда калын итеп киенеп, шыгырдаган кар өстеннән киез итекләр киеп йөрергә яратам мин. Шыгырт-шыгырт, шыгырт-шыгырт... Барасың да барасың... Рәхәт!

Кышкы уеннарны бик яратам. Куртка итәкләре чыланып, бозланып катканчы тауда чана шуу, егыла-егыла тимераякта шуу, җепшек көннәрдә кар тәгәрәтеп уйнау дисеңме – берсен дә читкә куймыйбыз. Болай батып кайтып керүебез әти белән әнигә дә, әби-бабамнарга да ошый. Бияләйләрдән су тамып, аяк киемнәребез бозга катып бетсә дә, нишләптер, берсе дә бер сүз әйтми.

**Рената Харитонова:**



Кем ничектер, мин беркем дә аяк басмаган тирән кар эчендә эз ясап йөрергә яратам. Үземне өр-яңа җирләр үзләштергәндәй хис итәм. Тун итәкләре бозланып, итек эчләренә кар тулып кайтып керәм. Итек табанына ябышкан карлы “үкчәләр”дә басып калып булмый, ишектән керү белән, таеп егылам. Мине “коткарырга” әти белән әни килеп җитәләр. И кызык та шул чакта. Мин көләм дә көләм, ә әни итекне салдыра алмый, чөнки ул тыгыз кар белән тулган. Әни ачуланган була, әти яклый: “Ярар, әнисе, ачуланма, шулай да уйнамагач, бала чактан нинди истәлек калсын,” - ди. Тирән итеп кар яуганны көтәм... Быел тагын шулай итеп урап кайтам әле☺.

**Зөһрә Закирова:**

Безнең гаилә – бик тату гаилә. Җәен дә, язын-көзен дә, кышын да әти-әниләр безгә төрле шөгыльләр табып кына тора. Бергәләп чаңгы шуабыз, шугалакка тимераякта йөрергә барабыз. Әти безне ял көннәрендә снегоходта йөртә. Без аның арбасына кереп утырабыз да тирән кар эченнән җәй көне җиләк җыйган болыннарга, көз көне гөмбә җыйган урман аланнарына барып чыгабыз. Һәр ел фасылының үз матурлыгы бар. Аны тоя белергә генә кирәк. Алда безне матур кышлар, күңелле истәлекләр көтә. Хуш киләсең, Яңа ел!

# БУЛАТ - ИҢ ШӘП ТАТАР ЕГЕТЕ




***“Ягез әле, егетләр! – 2017” республикакүләм бәйгесе Җиңүчесе – Мөслим гимназиясенең асыл егете, уку алдынгысы, ГТО буенча “Алтын” дәрәҗә иясе Булат Әхмәтҗанов белән әңгәмә.***

***Булат, үзең һәм үзеңнең мавыгуларың белән газета укучыларны таныштырып үт әле.***

Мин – Әхмәтҗанов Булат Алмаз улы. Мөслим районы Түреш авылындагы атаклы Әхмәтҗановлар нәселенең дәвамчысы. Җиде буын ата-бабамнан килгән традицияләрне саклап, чын татар егете итеп тәрбияләгән әти-әниемә, әби-бабама рәхмәтлемен.

Белгәнегезчә, бабам – балалар шагыйре Мөҗәһит Әхмәтҗанов. Мин аннан күп төрле һөнәрләргә өйрәнәм. Бергәләп нәсел шәҗәрәсен булдырдык. **Шәҗәрә ул** – нәсел-ыруның кемнән башланып, ничек тармакланып китүен күрсәткән кулъязма истәлек. Анда ата-бабалар исемлеге, нәсел тарихына бәйле вакыйгалар теркәлә. Фәнни нигездә билгеләмә биргәндә, **шәҗәрә** – генеалогик язма – туган-тумачалык, һәр шәхеснең тормышы һәм кылган хезмәтләре хакында мәгълүмат алып була торган тарихи чыганак ул. Шәҗәрә төзү – шәҗәрә агачы һәм буыннар тезмәсен барлау белән генә чикләнми. Нәсел, гаилә тарихы - илнең дә тарихы ул. Шәҗәрә һәр кешенең эшенә һәм тормыш юлына, күпсанлы кардәш-ыруның бәйләнешләренә ачыклык кертә. Гаилә тарихы аша кеше үзенең кемлеген, чыгышын, бу якты дөньяга нинди эшләр башкарырга килгәнлеген, туган нигезенең үткәнен, халкының тарихын, килеп чыгышын ачыклый ала. Без бүгенге көндә 11 буын бабаларыбызны ачыкладык. Алар арасында 8 буында музыкантлар булуы билгеле. Нәсел эшен дәвам итеп, мин дә музыка уен коралларында уйнарга өйрәнәм.

***Син “Ягез әле, егетләр!” республика конкурсында беренче урын алып кайттың. Музыкага сәләтең сиңа ярдәм иттеме?***

Әлбәттә. Конкурсларда музыкаль яктан сәләтле булу аерым бәяләнә. Мин бу турда белеп бардым. Конкурска видеоролик җибәрдек, конкурс таләбе буенча бер чыгыш сәләт күрсәтүгә нигезләнгән иде.

***Конкурсантлар арасында тагын нинди һөнәрле егетләр булды?***

Биючеләр, сәнгатьле сөйләм осталары, оста актерлар, гитарада уйнап җырлаучы егетләр бар иде.



***Тагын нинди төр сынаулар булды?***

«Белемлекнең чиге юк» дип аталган компьютер тестлаштыруы шактый катлаулы булды. Анда Татарстан тарихы, борынгы һәм хәзерге әдәбият, бүгенге көн татар дөньясы мәдәнияте, сәнгатенә, спортка караган сораулар күп иде. «Көчең барда көрәшеп кал, җегәрең барда ярышып кал!» дип аталган спорт бәйгесендә ГТО төрләре буенча көч сынаштык. «Серле сандык» конкурсында бер әзерлексез ясалган чыгышлар бәяләнде. Иң кызыгы - «Оста эшеннән билгеле» дигән конкурс булгандыр. Балалар күлмәгенә сәдәф тагып күрсәттек. Бер дә җиңел эш булмады ул. Иң соңыннан «Талантыңа җилкән тек, җил булмаса ишкәк ал!» дигән конкурс бөтен бәйгегә нокта куйды. Мин бөтен төр халык уен коралларында уйнадым: тальян гармун, таш сыбызгы, курай, сорнай һ.б. уйнавымны зал үз итте, жюри да яхшы бәяләде.

***Булат, конкурска берүзең бардыңмы?***

Юк, әлбәттә. Минем белән сыйныфташларым Айгөл Сабитова һәм Салават Зарипов булдылар. Дәртле биюләре белән алар минем һәрбер чыгышымны бизәп тордылар, һәр адымда миңа терәк булдылар. Форсаттан файдаланып, мин аларга үземнең зур рәхмәтемне белдерәм. Дуслар шундый чакта сынала.

***Мондый конкурслар сиңа нәрсә бирә?***

Конкурсларда чын конкуренция бара. Башкалардан калышмаска, сынатмаска тырышып янасың, көясең. Мондый бәйгеләр үз асылыңны аңларга, үз-үзеңне бәяләргә өйрәтә. Җиңү ләззәтен тату рәхәт инде. Кайвакыт җиңеләә белергә дә кирәк. Ансы да була. Тормышта ныгу өчен барысын да үтәргә кирәк, минемчә.

***Булат, җавапларың өчен рәхмәт. Сиңа уңышлар телибез.***

***Салихова Динара, 11 нче а сыйныфы укучысы***

ТЫЛСЫМ+
Декабрь, 2017 нче ел
*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Исмәгыйлева Язилә
**Корректорлар:** Шамукаева Эльвина, Солтанова Эльвина
**Корреспондентлар:** Салихова Динара, Кашапова Илүзә
**Дизайнер:** Галиев Илназ

**Компьютерда җыючылар:** Гилемов Азат, Шарифуллин Заһир
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym